**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ РАЙОН СОВЕТЫ**
**(IV чакырылыш)**

IV чакырылыш чиратан тыш утырыш
**КАРАРы**

07 март 2023 ел №8 Урыссу ш.т.п.

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Әбсәләм авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең
Генераль планына үзгәрешләр кертү проектын раслау турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 14.03.2022 ел, 58-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Территорияне планлаштыру документларын, шәһәр төзелеше планнарын әзерләү, капиталь төзелеш объектларын төзүгә рөхсәт бирү, файдалануга кертүгә рөхсәтләр бирү үзенчәлекләре турында» 02.04.2022 ел 575 номерлы карары, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль берәмлегенең «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башлыгының «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы "Әбсәләм авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең генераль планына үзгәрешләр кертү проекты буенча ачык тыңлаулар билгеләү турында» 06.02.2023 ел, № 9 карары белән, 2023 елның 7 мартындагы Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Әбсәләм авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертү проекты буенча гавами тыңлаулар беркетмәсен һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Әбсәләм авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертү проекты буенча ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында 2023 елның 7 мартындагы бәяләмәсен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Ютазы район Советы карар кабул итә:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Әбсәләм авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең генераль планына үзгәрешләр кертү проектын расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга һәм http://jutaza.tatarstan.ru/ Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Рәсми Татарстан»

дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының бердәм порталы составында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Ютазы район Советының Экология һәм җирдән файдалану буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башлыгы -
Татарстан Республикасы
Ютазы район Советы Рәисе А.Ә. Шәфигуллин